РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН ГЛАВА ГАЙТАНКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ГӘЙТӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

423014, РТ, Нурлатский район, с. Гайтанкино, ул. Садовая, дом 17,
Тел. 8 (84345) 3-98-01

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» март 2024 ел № 1

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлегенең Гәйтән торак пунктында гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гәйтән авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гәйтән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 8 апрелендә 13 сәгать 00 минутка Үзәк урамы 13нчы йорт адресы буенча клуб бинасы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлегенең Гәйтән торак пунктында яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Халык җыены этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты белән тәэмин ителә.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез элек расланган гражданнар җыенына чыгарылган сорауларга үзгәрешләр кертүгә ризамы:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлегенең Гәйтән торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 03.11.2023 ел № 7 карары.

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлегенең Гәйтән торак пунктында гражданнар Җыенының 03.11.2023 ел, №8 карары,

аны түбәндәге редакциядә раслап:

«2024 елда Нурлат муниципаль районының Гәйтән авыл җирлеге Гәйтән авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту.
2) урам яктырту җайланмасы.
3) су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын,

скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.

4) торак пункт территориясен төзекләндерү.
5) Ремонт, коймалар төзү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү.

« РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гәйтән авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Гәйтән авыл җирлеге башлыгы Н. В. Авдеева